Җәмгыять, гаилә, кеше – иң тыгыз бәйләнештә яши торган төшенчәләр. Дәүләтнең нигезен формалаштыруда мөһим роль уйнаган гаиләнең хәле, яшәү рәвеше һәм ныклыгы илнең бүгенгесен һәм киләчәген, икътисадый һәм мәдәни тотрыклылыгын билгели. Шул ук вакытта иҗтимагый барыштагы тарихи-сәяси һәм мәдәни шартлар җәмгыять белән бергә гаилә яшәешенә дә хәлиткеч йогынты ясый. Шунлыктан кешелек тарихындагы ерак үткәнне күздән кичерсәк, һәр чорның үзенә хас гаилә моделе булганын күрәбез. Гаиләнең үз эчендәге, үз әгъзалары арасындагы яшәү кануннары һәм башка гаиләләр белән мөнәсәбәтләре һәр этник-милли культурада аерым бер үзенчәлеккә ия, ягъни гаилә тормышында бу чорның сыйфатлары «яши». Моның белән бергә, чорына карап, гаилә эчендәге кешеләр һәм буыннар саны, ягъни гаилә модельләре дә үзгәреш кичерә. Төрек белгече Гыясетдин Ауташ язганча, гаилә типлары эчендә өч төрле группа күзгә ташлана: киң гаилә типлары; кечкенә гаилә типлары һәм өченчесе – модерн (заманча) гаилә типлары [1: 8].

Һәр чорның социокультурологик шартлары нигезендә формалашкан гаилә тибы бар, дидек. Әйтик, кабиләчелек чорында яки күчмә тормыш рәвеше белән көн итүче халыклардагы *гаилә* төшенчәсе җирле халыклардагы гаилә тибыннан аерыла. Шул чор белән бергә дини ышанулар да гаиләнең эчке моделенең, яшәү шартларының һәм рәвешенең формалашуына тәэсир ясый. Мәсәлән, элек-электән татарларда һәм төрекләрдә гаиләнең яшәү рәвеше ислам дине кануннарына нигезләнгән. Һәр милләт мәдәниятенең һәм традицияләренең формалашуында берләштерү көченә ия булган дин мөһим роль уйный. Ислам динендә гаиләгә һәм ир-хатын мөнәсәбәтләренә зур әһәмият бирелә. Мәҗүсилек чорыннан килгән гадәтләрне ислам дине, чынлап та, кешелекле мөнәсәбәтләр кысасына урнаштырып, гаиләнең гуманлы моделен төзи. Дин ныклы һәм әхлаклы җәмгыятьнең төп нигезен гаиләдә, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрдә һәм кеше рухи

дөньясының чисталыгында күрә. Иман-инану кешелек өчен зарури булган әхлакый кыйммәтләрне саклый.

Яшәү рәвешен дин-шәригать кануннары билгеләгән чорларда, бигрәк тә авыл җирлегендә яшәгән татарларда, өч буыннан торган традицион гаиләләр киң таралган күренеш була. Бер түбә астында яшәгән өч буынның өч төрле яшәү рәвешен, өч төрле дөньяга карашын үз эченә алган гаиләләрдә бу катлаулы эчке атмосфераны тәртиптә тотуның үз эчке кагыйдәләре булган. Шуның өстенә, татарлар арасында кардәш-туганнарны берләштергән катлаулы гаиләләр дә таралыш тапкан була. Бу төр гаиләләр якын туганнарның күрше булып яшәүләреннән гыйбарәт. Зур хуҗалыкны алып бару, бер-береңә ярдәм итү туганлык җепләрен ныгыткан, өлкәннәргә, бер-берсенә хөрмәт белән карарга өйрәткән [2: 40]. Гаиләдәге өлкәннәргә хөрмәт хисе белән тәрбияләнгән яшь буын җәмгыятьтә дә башкаларга ихтирам белән караган. XX гасырда илдәге сәяси-тарихи атмосфераның үзгәрүе татар гаиләсе эчендәге рухи кыйммәтләрнең һәм гаилә типларының да үзгәреш кичерүенә сәбәп була. Замана алмашынуы тәэсирендә берничә буынны үз эченә алган традицион гаиләләр азаюга таба бара, нигездә, авылларда гына сакланып кала. Мөстәкыйльлекне яратучы яшьләр ата-ана һәм баладан формалашкан кечкенә гаилә тибын өстен күрә башлый. Гаиләдә өлкән буынның булмавы, әлбәттә, гаилә эчендәге традицион гадәтләрнең, дини йолаларның һәм үткән белән бәйләнешнең өзелүенә китерә. Баласыз гына, үз рәхәтләрен генә күреп яшәргә теләүче заманча гаиләләр исә милләтнең киләчәгенә афәт тудыра, чөнки татарларда гаилә төшенчәсе милләт һәм дәүләтчелек төшенчәсе белән тыгыз бәйләнгән. Гаилә эчендә бирелгән милли тәрбия, милли үзаң һәм әхлакый кыйммәтләр генә татар милләтенең киләчәге ныклы булачагына ышаныч тудыра ала.

Кеше-гаилә-җәмгыять мөнәсәбәтләре социологлар һәм педагогларның гына түгел, язучыларның да игътибарын үзенә тарта. Җәмгыятьтәге милли-әхлакый кыйммәтләрнең юкка чыга бару сәбәпләрен гаилә проблемасы белән бәйләп караган, гаилә таркалуның җәмгыять һәм милләтнең тотрыксызлануына китерүен аңлаган татар һәм төрек әдипләре бу җитди теманы үз иҗатларында сәнгатьчә гәүдәләндерәләр.

Урта гасыр татар әдәбиятында гаилә, хатын-кыз мәсьәләләре тасвирлануга шәрык традицияләре белән дин, шәригать кануннары зур йогынты ясый. Дөньяви эчтәлекле әсәрләрдә югары катлау – патша, хан кызлары – матурлыгына дан җырлана, аларның эш-гамәлләренә мәдхия укыла. Шул ук вакытта гаиләнең ныклы нигезен тәшкил иткән кыйммәтләрнең контуры барлана башлый. Татар-болгар ядкәре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (1212) поэмасында яшьлегендә Йосыф тарафыннан кире кагылган Зөләйха, тугрылыгын һәм аңа булган хисләрен саклавы нәтиҗәсендә, яшьлегенә кире кайтып, Йосыфка кияүгә чыгу бәхетенә ирешә, бәхетле гаиләнең нигезе булган мәхәббәт тантана итә [3: 153]. Мәхмүд Болгари, Котб, Сәйф Сараи, Харәзми әсәрләрендә гәүдәләнгән әхлакый проблемалар да гаилә мотивлары белән кушылып китә. Бу яктан XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый хикмәтләре аеруча гыйбрәтле: «Мәүла Колый тигез мәхәббәткә корылган гаилә тормышын мактый, бала тәрбияләүне ата-ана өчен зарури эш дип саный» [4: 46]. Гаиләдә хатын-кызның роле, аңа хас күркәм-матур сыйфатлар, ир-ат күңел дөньясында хатынының урыны кебек мотивлар XVIII йөз шагыйре Габдерәхим Утыз-Имәни мәрсияләрендә чагылыш таба [5: 136].

Милли идеяләр көчәя башлаган һәм шәхес проблемасын үзәккә алган XIX гасыр татар әдәбиятында гаилә темасына аеруча киң урын бирелә башлый. Мәгърифәтче язучылар шәхеснең формалашуын гаилә эчендәге тәрбиягә, ата-ананың роленә бәйләп карыйлар. Белемле һәм тәрбияле шәхес үстергән гаиләләр язмышында татар тормышының ныклы киләчәген күрәләр. Муса Акъегетнең («Хисаметдин менла», 1895), Закир Һадинең («Бәхетле кыз», 1904), Риза Фәхретдиннең («Әсма, яки гамәл вә җәза», 1903) әсәрләрендә [6] Ислам дине кагыйдәләренә, милли гореф-гадәтләргә һәм заманча мөнәсәбәтләргә нигезләнгән үрнәк гаилә типлары тудырыла. Гаилә бәхете ир-атның һәм әйләнә-тирәнең хатын-кызга уңай мөнәсәбәтендә ачыклана.

Татар халкының кискен иҗтимагый-рухи, мәдәни үзгәрешләре чоры XX гасыр башы татар әдәбиятында гаилә темасының үзенчәлекле сурәтләнеше күзәтелә. Билгеле булганча, XX гасыр башында моңа кадәр шәркый традицияләр, Ислам мәдәнияте йогынтысында яшәгән татар халкы Европа мәдәниятенә йөз белән борыла, европача, русча яшәү үрнәгенә омтыла. Яңа татар әдәбиятында

кеше бәхете проблемасы, фәлсәфи төсмер алып, иҗтимагый-милли яссылыкта сурәтләнә башлый: ир-хатын, килен-кайнана, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре иске татар тормышын асылыннан үзгәртеп кору идеяләре белән тыгыз үрелеп күрсәтелә, һәм соңгысы үз чиратында гаилә буыннары – «ата» һәм «бабалар» мөнәсәбәтләрен тагын да кискенләштереп җибәрә. Кешенең бәхетле булу-булмавы нинди шартларга, сәбәпләргә бәйле дигән сорауларга җавап эзләнә. Иҗтимагый-рухи яңарыш милли чынбарлыкта милләтнең яртысын тәшкил иткән хатын-кызга карашны, аның гаиләдә генә түгел, ә җәмгыятьтәге урынына да мөнәсәбәтне уңай якка үзгәртүне көн тәртибенә куя. Гаилә кору, угылны өйләндерү, кызны кияүгә бирү йола, гореф-гадәтләрендә дин-шәригать кануннарының көче шактый кимеп, никах иреге яклана башлый. Ә алар, үз чиратында, гаилә кыйммәтләренә сизелерлек тәэсир ясый. Менә шушы шартларда Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Камал һ.б. сәнгати сурәтләнешенең гаҗәеп бай традицияләре булган хатын-кыз һәм гаилә темаларын үз әсәрләрендә чагылдыралар. Милләт һәм кеше язмышында гаиләнең мөһим ролен аңлаган Гаяз Исхакый иҗатында («Өч хатын берлә тормыш», 1900; «Бай угълы», 1903; «Алдым-бирдем», 1907; «Остазбикә», 1915 һ.б.) [7] бәхетсез гаиләләрнең сәбәпләре күрсәтелү белән бергә үрнәк гаилә модельләре дә иҗат ителә. Шул ук вакытта хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге урынына һәм бурычларына караш та үзгәрә: ул акыллы хатын һәм кайгыртучан ана гына түгел, бәлки милләтнең алга китешендә үзеннән өлеш кертүче көрәшче зат буларак та сурәтләнә.

Романтик ысулда иҗат ителгән әсәрләрдә мәхәббәт темасына өстенлек бирелү табигый. Ф.Әмирханның «Хәят» (1911), Г.Исхакыйның «Мөгаллимә» (1913), М.Фәйзинең «Тәкъдирнең шаяруы» (1913), К.Тинчуринның «Соңгы сәлам» (1917) [8] һ.б. әсәрләрдә ир белән хатын арасындагы тигез мәхәббәткә корылмаган, матди кыйммәтләргә өстенлек бирелгән гаиләләрдә кеше бәхете тулы була алмый, гаилә кыйммәтләре дә зәгыйфьләнә, «бәхеткә дә, ямьгә дә, күңел тынынычлыгына да урын юк» [9: 43] дигән фикер үткәрелә.

Октябрь инкыйлабына кадәрге татар гаиләсе эчендәге катлаулы яшәү моделе – ир–хатын, килен – кайнана-кайната, туганлашкан ике нәселнең унай яки каршылыклы мөнәсәбәтләре – Галимҗан Ибраһимовнын совет чорында яңа вариантта язылган (беренче вариант 1908 елда языла) «Татар хатыны ниләр күрми» (1923) повестенда һәм «Казакъ кызы» (1924) [10] романында аеруча киң планда тасвирлана. Бу әсәрләрендә әдип хатын-кыз язмышын һәм шәхес иреге мәсьәләсен, милли традицияләргә бәйләп, зур осталык белән тасвирлый. Гаиләнең кануннар белән чикләнгән «ябык система» булуын, җәмгыятьнең гомуми законнарына да бәйле икәнлеген сәнгатьчә чаралар ярдәмендә исбатлый. Гөлбануның фаҗигале язмышы, рәхимсез кайнана ихтыярында булуы кырыс чынбарлыкның нәтиҗәсе буларак тасвирланса, казакъ даласының чиксез иркенлегендә үскән Карлыгач-Сылуның киләчәге дә ыруглар арасындагы, гаилә эчендәге кануннар «читлегенә» бикләнгән. Шулай да бу героинясының язмышын Г.Ибраһимов романтик планда хәл итә: әсәр Арысланбай белән Карлыгачның гына түгел, казакъ иленең дә киләчәге «…кызыл уттай яна башлаган ерак таңга таба» борылган булуын хәбәр итеп тәмамлана.

Совет илендәге сәясәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә совет әдәбиятында гаилә төшенчәсенә идеологик мөнәсәбәт формалаша. Моңа кадәр аерым кеше бәхетен һәм милләт киләчәген гаилә тормышына гына бәйләп караган бер төркем язучылар икенче чиккә тайпылалар: хатын-кызның азатлыгын аның гаиләдән «азат» булуы дип күз алдына китерәләр. Кешелекнең яшәү рәвеше булган гаилә кору, бала үстерү кебек зарури күркәм гадәтләр, мещанлык күренеше итеп, тискәре бәяләнә башлый. Башта бу шаукымга бирелеп алган язучылар үзләре үк мондый «яңалыкның» реаль нәтиҗәләрен тасвирлап күрсәтәләр: бүген дә актуальлеген югалтман әсәрләр иҗат итәләр. Мәсәлән, Һади Такташның «Югалган матурлык» (1929) [11] роман-пьесасында Галия укымышлы, партия-комсомол эшендә дә заманча актив. Ләкин көннәрен комсомол һәм җәмәгать эшләрендә уздыру сәбәпле, гаиләсенә һәм баласына вакыт аера алмый. Нәтиҗәдә, яшәү мәгънәсе булган баласын, гаиләсен һәм мәхәббәтен югалта. Яңа җәмгыятьнең үрнәк гаиләсен төзиячәкләренә ихлас ышанган геройлар яңалыкны тулысынча традицияләрдән ваз кичү дип уйлап ялгышалар. Һ.Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) [12] поэмасында да яңалык эзләү юлындагы тайпылыш – «ирекле мәхәббәт» шаукымына бирелү нәтиҗәсе икәнлеген тасвирлый һәм иң гадел, табигать

кануны булган сүзләрне язып калдыра: «хатын-кызның бөтен матурлыгы, бөтен күрке – ана булуда».

Гадел Кутуй «Тапшырылмаган хатлар» (1935) [13] повестенда гаилә тормышына җитди караучы, үз бәхете өчен генә түгел, бәлки киләчәк буынны тәшкил итүче балаларның бәхете өчен дә җаваплылык хис итүче Галия образын иҗат итә. Ул һәр нәрсәгә җитешә: белемен дә арттыра, балаларына ана назын, тиешле тәрбиясен бирә. Шул ук вакытта, җәмгыять тормышыннан да читтә калмыйча, кешеләргә кирәкле, файдалы хезмәт белән яшәргә омтыла, талантлы врач булып таныла. Ирекле мәхәббәткә дәгъва кылган Искәндәр исә ата булу вазифасыннан һәм гаилә җаваплылыгыннан кача. Искәндәрнең, үзенең талантлы артист булуына гына өстенлек биреп, хатыны Галиягә кимсетеп каравы һәм аңа хыянәте гаиләнең җимерелүенә китерә. Атасыз гаиләнең тулы була алмавын аңлаган язучы Галиянең юлына балалары өчен үрнәк ата булырлык Вәли Сафиуллинны чыгара. Замана шаукымына каршы тору өчен, гаилә эчендә ир-хатын арасында үзара хөрмәт, сабырлык һәм тугърылык кебек «эчке кануннар» әһәмиятле. Кешелекле бу сыйфатлар җәмгыять тормышына гаиләдән күчә дигән нәтиҗә җиңел аңлашыла.

Татар әдәбиятының сугыштан соңгы чорында да кеше-гаилә-җәмгыять мөнәсәбәтләре игътибар үзәгендә калды. Шул ук вакытта, тормыш барышы традицияләргә дә үзгәрешләр кертте. Иҗтимагый тормышта шәхеснең роле активлаша барган саен, кеше тормышында гаилә икенче пландагы рольне үти башлады һәм бу шулай булырга тиеш кебек иде. Ләкин бу проблеманың никадәр катлаулы һәм төрле сәбәпләргә бәйле икәнлеге әдәби әсәрләрдә тасвирлана барды. Бу, мәсәлән, Әмирхан Еники повестьларында аеруча игътибар белән анализланды һәм төрле язмышлы кешеләр мисалында расланды. Мәсәлән, «Саз чәчәге» (1955) [14] әсәренең герое – райком секретаре булып уңышлы эшләп килгән Шакир Мостафин – эшендә һәм тормышында терәк булган, акыллы хатыны һәлакәтеннән соң, икенче районга күчеп килә. Чибәр, әмма саз чәчәге кебек тышкы матурлыкка гына ия булган җилбәзәк кызга өйләнә. Майпәрвәз «ханым» тәрбиясен алган Наҗия белән корган гаилә Шакир өчен сазлык, түбән тәгәрәү булып чыга. Ул хыял-максатларыннан аерыла, яраткан эшеннән мәхрүм кала, шәхес буларак та үзен югалта. Мондый гаилә кемне бәхетле итә ала – ирнеме, ирен үзенә буйсындырып яшәү максатын куйган хатыннымы? Гомумән, бәхетле яшәү нинди була? Бу сорауларга җавапны әдип башка әсәрләрендә, төрле геройлары һәм төрле гаилә типлары мисалында иҗат итә. Һәр очракта укучыларын уйландырырлык сораулар да куеп калдыра. «Рәшә» (1962) [14] повесте акыллы, тырыш һәм барысын да алдан уйлап куеп яши торган Зөфәр язмышын тасвирлый. Алдына куйган максатка ирешү өчен, ул Рәшидәгә булган мәхәббәтеннән дә баш тарта; башкалардан өстен булып, бай һәм ирекле тормыш корып куя… һәм, упкын читенә килеп җиткәндә, үзенең беркемгә дә кирәк булмавын, бушлык эчендә калуын аңлап ала. Исәп-хисапка гына корылган «курчак» гаилә дә чын шәхси бәхет түгел икәнлеге аңлашыла. Кайда ялгышты соң Зөфәр? Кем гаепле аның шундый хәләттә калуына? дигән сораулар әле дә безнең алда тора.

«Төнге тамчылар» (1964), «Тынычлану» (1978) [14] әсәрләрендә зур галим дәрәҗәсенә ирешеп тә, мәхәббәтенә хыянәт итеп, шул хыянәте бәясенә корылган гаиләдә бәхетле була алмау яки гаиләдә тавыш чыкмау «хакына» корып куелган пассив «тынычлык» – тормыш арбасыннан төшеп калу, кадерсез, кирәксез булып, үзеңне алдап яшәү икәнлеге психологик осталык белән тасвирланган.

XX гасыр ахырында җәмгыятьтәге үзгәрешләр тормышка һәм яшәү кыйммәтләренә карашларны үзгәртте. Бу хәл кешенең яшәү рәвешенә, гаилә тәртипләренә дә йогынты ясамый калмады, әлбәттә. Җәмгыятьтәге тотрыксызлык гаилә кануннарын да, кешенең эчке дөньясын да какшатты. Язучылар сәбәпләрнең бүгенге көн белән генә бәйле булмавын, еракта килгән тамырлар белән бәйле икәнлегенә үзләре үк шаһит иделәр. Мәсәлән, Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» (1989) [15] романы, исеме белән үк сискәндереп, хакимият белән халык арасындагы каршылыкларның рәхимсезлеген «күзгә күренмәс» җепләр белән чорналган шәхси язмышлар мисалында тасвирлады. Кеше характеры, нинди шартларга куелуына карап, ни дәрәҗәдә үзгәрүчән, яраклашучан яки яраклаша алмаучан да булуын сурәтләп, автор кеше күңеленең иң яшерен серләрен дә фаш итеп бара. Кеше күңеленә кереп урнашкан курку хисе көчле характерлы Нәҗипне кол хәленә төшерә, нык ихтыярлы хатыны Наиләне

иренә хыянәт итеп яшәргә мәҗбүр итә. Мондый гарип гаилә корылуга сәбәпче булган явыз система турында чаң суга әдип. Соңрак автор нәкъ менә гаиләдә кешене шәхес итеп формалаштыруда нигез салыну проблемасына яңадан әйләнеп кайта. Гаилә моделе «йорт», «әти», «әни» традицион образлары аркылы оештырылып, «әти кеше тормыш кагыйдәләрен өйрәтүче мөгаллим», «ана образы милли яшәеш нигезләрен өйрәтүче, милли кыйммәтләрне тәрбия кылучы» буларак тәкъдим ителә [16: 592-594].

Хәзерге чор язучыларыннан Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» (2001-2007) [17] исемендәге роман-трилогиясе дә совет чорында җәмгыятнең гаилә тормышына тәэсирен, шәхес трагедиясен җанлы буяулар ярдәмендә яктыртуы белән кызыклы. Романда гаҗәеп олы идеаллар белән яшәүче, кешелек тарихында яңа борылышлар ясарга теләүче Ирек Сабитовның, дәртләнеп, партия сафларына керүе, партия райкомына инструктор булып урнашкач, «өстәгеләр» тарафыннан талантын үз мәнфәгатьләренә җигеп, аны рухи имгәтүләре, сындырылуы тасвир ителә. Ирек хезмәт иткән тирәлек аны үз кубызына биетә, үзе теләгәнчә эшләтә. Партия эшенә бөтен җаны-тәне белән бирелгәнлектән, гаиләсенә тиешле игътибары калмый. Ул үз хатасын коточкыч упкынга төшкәч, гаилә фаҗигасен кичергәч кенә аңлый. Романда гаделлек бозылган, икейөзлелек хакимлек иткән шартларда кеше бәхет дип санаган яшәү рәвеше гаиләне дә кайгы-хәсрәт эчендә яшәтә икәнлеген автор төп геройлар Ирек белән Зәнфирә мисалында, авыл кешеләре язмышында каршылыклы хис-кичерешләр, ялгышу һәм алданулар мисалында раслый.

Узган гасырның туксанынчы еллар татар әдәбиятына галим һәм тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин килеп кушыла. «Замана балалары» (1993), «Дәгъва» (1995) әсәрләреннән башлап, шәхес һәм гаилә язмышлары яшәп килгән системага, иҗтимагый шартларга аерылгысыз рәвештә бәйле икәнлеген дәлилле анализлап иҗат итә. Аның «Тәүбә» (1997), «Элмәк»(1998) романнарын йомгаклаган «Сәет Сакманов» (2005) [18] исемле роман-трилогиясе – хәзерге заманның гәүдәләнеше булган күренекле әсәрләрнең берсе. Вакыйгалар эзеннән генә барганда нәтиҗә ясау куанычлы түгел: Сәет Сакмановның үзе теләгәнчә яшәргә хокукы булмау гына түгел, ул яраткан кешесен дә, гаиләсен дә саклап кала алмый, үзе дә һәләк була. Хикмәт аның шәхси сыйфатларында гына да түгел. Сәет – үз чоры, заманы «тудырган» шәхес. Заман «тәкъдим иткән» шартларны кабул итеп, заман белән «бил алышып» яшәргә теләгән шәхес. Әмма заман аны үз чоңгылына йотып ала. Бу образның «балачагын» Ә.Еники иҗат иткән Зөфәр язмышында күрәбез кебек. Татар әдәбияты үз тарихында заман геройларын эстафета кебек чордан-чорга тапшырып бара.

Мөстәкыйль дәүләтчелеккә ия булуга карамастан, төрек җәмгыятендәге гаиләләр дә тарихи чорлар хәрәкәтендә төрле мәдәни үзгәрешләргә дучар була. Кайсы чорда һәм кайда яшәвенә карап, гаилә моделе һәм эчке мөнәсәбәтләр үзгәрә. Авыл җирлегендә көн итүче гаилә белән шәһәрдә яшәүче гаилә арасында зур аерма күренә. Татарлардан аермалы буларак, төрекләрдә электән авылларда «ана, ата һәм араларында кан туганлыгы булган икенче һәм өченче буын туганнарның да бер арада яшәгән киң гаиләләр» очрый. Киң гаиләләрдә туганлык җепләре көчле, ирләр, гаилә башлыгы буларак, бөтен мәсьәләләр өчен җаваплы булган. Мәхмүт II заманында (идарә иткән еллары 1808-1839 еллар) туфрак реформалары башлангач, гаиләдәге ир балаларга тигез рәвештә җир бүлеп бирелү сәбәпле, традицион киң гаиләләр кечкенә гаиләләргә бүленә башлый [19: 2]. Шулай да ул үзенең асыл үзенчәлеген – ата культының көчен югалтмый, ул гаиләнең терәге һәм туендыручысы булып кала. Бу төр гаиләдә хатын-кызның урыны икенче планда кала килә, ул, беренче чиратта, бала тудыручы һәм кыр-бакча эшләрендә иренә ярдәм итүче вазифасын башкара.

Төрек җәмгыятендә шәһәр культурасы гаиләнең эчке кагыйдәләренә аеруча көчле тәэсир итә. Белгәнебезчә, Европа каршында шактый көчсезләнгән Госманлы дәүләтенең соңгы гасырында, ягъни 1839 елда, рәсми рәвештә, Танзимат (яңа тәртип) карары игълан ителә. Нәтиҗәдә дәүләт күләмендә сәяси, хәрби һәм икътисадый өлкәләрдә яңарышка, өр-яңа бер мәдәниятқә – Европа казанышларына омтылу чоры башлана [20: 28]. Моңа кадәр Шәрык традицияләренә нигезләнеп гомер иткән төрек тормышына Гареб гадәтләренең үтеп керә башлавы гаилә мәсьәләсе тирәсендә дә төрле бәхәсләр тудыра. Кайбер кешеләр гаилә төзелешендә төрек-ислам гадәтләрен якласа, икенчеләре Европадан килгән фикерләрне хуплый. Төркичелек фикерен яклаучы күренекле

Зыя Гөкальп исә, Европадагы ир-хатын тигезлеге һәм төрек әхлагы бергә яшәгән «милли гаилә» тибын тәкдим итә [21: 4].

Гаилә типларының, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрнең үзгәреш кичерүе, татарлардагы кебек, төрек тормышында да гаиләдә һәм җәмгыятьтә хатын-кызга булган мөнәсәбәтнең үзгәрешенә бәйле. Госманлы чоры әдәбиятында хатын-кыз төрле чагыштыру-охшатулар ярдәмендә хыялый бер образ итеп тасвирланса, Европа әдәбиятыннан тәэсирләнгән Танзимат чоры әсәрләрендә ул чынбарлык вакыйгалары фонында тормышчан образ итеп сурәтләнә башлый. Хатын-кыз, ислам гадәтләренә күрә әхлаклы, гаилә учагын саклаучы һәм яхшы ана булу сыйфатлары белән бергә, белемле һәм җәмгыять эшләрендә актив зат итеп тудырыла. «Ибраһим Шинаси, Нәмык Кямал, Зыя Паша нигез салган һәм Әхмәт Мидхәт, Габделхак Хәмит, башкалар аерым юнәлешләрен тудырган, үстергән бу яңа әдәбиятта, гасырлар буена формалашкан эстетик нормалар җимерелеп, алар урынына яңалары барлыкка килә. Анда хатын-кызның гаиләдә, җәмгыятьтә тигез хокуклы булырга тиешлеге, дөньяви белем, заманча тәрбия бирү, халыкны томаналыктан алып чыгачак фән, мәдәният тудыру идеяләре чагыла башлый…» [22: 29]. Гаиләдә һәм җәмгыятьтә ир-хатын тигезлеге, хатыннарның белем алудагы хокуклары мәсьәләләре беренчеләрдән булып Әхмәт Мидхәтнең (1844-1912) «Хатыннар фәлсәфәсе», («Felsefe-i Zenan», 1870) [23] әсәрендә күтәрелә. Язучы хатыннарның матди яктан бәйсез булырга тиешлеге, кияүгә чыкмыйча да үз тормышларын алып барырга сәләтле икәнлеге фикерен әсәр герое Фазыла ханым язмышына бәйләп уздыра. Тәрбияле һәм укымышлы Фазыла ханым, гаилә эчендә әсир булырга теләмәгәнлектән, кияүгә чыгудан баш тарта. Яшәү мәгънәсен башкаларга ярдәм итүдә, аеруча төрек кызларын караңгылыктан коткаруда күрә: тәрбиягә Акилә һәм Зәкия исемле ике кыз алып, аларның белемле булуы өчен күп көч куя. Башка бер әдип Нәмык Кямал (1840-1888) исә җәмгыять тотрыклылыгында гаиләнең әһәмиятле роль уйнавын ассызыклый. Гаиләдә ана-бала, ир-хатын, килен-кайнана мөнәсәбәтләрен искелек белән яңалык бәрелеше аспектында сурәтләгән «Уяну» («İntibah», 1876) [24] романында, татар мәгърифәтчеләре кебек, шәхеснең киләчәк язмышында гаилә тәрбиясенең әһәмиятле икәнен исбатлый.

Танзимат (1859-1895), аеруча Сәрвәт-и Фүнун (фән байлыклары мәгънәсендә килә, 1896-1901), икенче төрле әйткәндә, җәдитчелек әдәбияты язучылары сурәтләү объекты итеп башлыча Истанбулның югары катлау гаиләләрен һәм гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрне ала. Ул чор төрек прозасында Нәбизадә Назыймның «Зөһрә» («Zehra», 1894), Халит Зыя Ушаклыгөлнең «Тыелган мәхәббәт» («Aşk-ı Memnu», 1901), Мәхмәт Рәүфнең «Сентябрь» («Eylül», 1901) [25] кебек мәшһүр романнарында гаилә-җәмгыять бәйләнеше һәм катлаулы гаилә төрләре сурәтләнә. Аларда шул чор җәмгыятенә хас социаль-әхлакый үзгәрешләр җәмгыятьнен кечкенә парчасы саналган гаилә эчендә яктыртыла, ягъни европача яшәү рәвешен сайлаган төрек гаиләсе моделе аша шул чор җәмгыятенә бәя бирелә. Романнардан күренгәнчә, бернichә катлы зиннәтле йортта, нигездә, өлкән буын, урта буын, балалар һәм хезмәтче яки җарияләрдән оешкан зур гаилә бер түбә астында яши. Өлкән буын кешеләре госманлы чоры әхлагы һәм тәрбиясенең үрнәге итеп бирелсә, ул-килен һәм оныклар европача яшәүчеләрнең вәкиле сыйфатында килә. Бу төр гаиләләрдә каршылык, башлыча, төрле буынның тормышка һәм гаилә эчендәге яшәү рәвешенә карашларының төрле булуына нигезләнсә, икенче яктан, тышкы тәэсирләр йогынтысында ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең какшавында да күренә. Мәсәлән, таркалган гаилә язмышын яктырткан «Зөһрә» романында гаилә бәхетен һәм тынычлыгын бозуда Зөһрәнең көнчелеге, ире Сөбхинең оясына һәм хатынына хыянәте, кайнанасының гаилә бердәмлеген саклап калуда битарафлыгы әһәмиятле факторлар итеп алга чыгарыла. Кайбер әсәрләрдә (Ушаклыгөл Х.З. «Тыелган мәхәббәт», Рәүф М. «Сентябрь») гаиләнең нигезен тәшкил иткән мәхәббәт һәм тугрылык төшенчәләренең, заман шаукымына бирелеп, яшерен мәхәббәт хисләре һәм хыянәт нәтиҗәсендә тапталуы, гаилә эчендәгеләрнең тирән газаплар кичерүе тирән психологик осталык белән сурәтләнә. Романнарда мондый төр гаиләләрдә балаларның заманча белем алуына, чит ил укытучылары ярдәмендә сәнгать, музыка белән шөгыльләнүенә, башка телләр өйрәнүенә зур әһәмият бирелү, икенче яктан, электән килгән рухи кыйммәтләрнең гаилә эченнән акрынлап кысрыкланып чыга баруы яктыртыла.

Яңа төзелгән Төрек республикасының (1923) беренче елларыннан ук гаилә төзелешендә дә үзгәрешләр кертелә башлый. Азатлык сугышында бик күп санда корбаннар биргәнлектән, илдә хатын-кызның, беренче чиратта, ана булу вазифасы алга чыгарыла, бала үстерү ватан бурычы итеп санала. Дәүләт тарафыннан хатыннарның белем алуы һәм эшкә урнашуы да әһәмиятле шартлардан берсе итеп билгеләнә [26: 238]. Соңгы фикер мәшһүр романчы Халидә Әдип Адыварның (1884-1964) күпчелек әсәрләрендә төп мотив төсендә уздырыла. Аның героинялары европача карашлы, көчле рухлы һәм үз ирекләре өчен көрәшүче феминист затлар буларак аерылып тора. Җөмһүрият чоры әдәбиятының (1923 елдан башлап бүгенгә кадәр) башлангыч чор язучыларыннан Решат Нури Гөлтекинның «Куаклык кошы» («Çalıkuşu», 1922) [27] романындагы Фәридә образы да киң катлау укучыда онытылмас якты эз калдырган «яңа яшь бер кыз тибы» [20: 406] булып санала. Маҗараларга омтылу, үзенә хыянәт итте дип уйлаган сөйгәне Кәмрахтан качу һәм үзен раслау, тамагын туйдыру өчен акча эшләү теләге Фәридәне Анадолуның караңгы һәм артта калган авылларына китерә. Төрле каршылыкларны җиңеп, үз намусын саклап калган бу максатчан һәм фидакарь кыз берничә буын «төрек укымышлыларын, аеруча, кызларны авылларда укытучылык эшенә илһамландыра» [20: 406].

Җөмһүрият чоры язучыларыннан социалистик реализм методы тарафдары, прозаик һәм драматург Орхан Кямалның (1914-1970) «Кечкенә ирнең романы» («Küçük Adamın Romanı») сериясеннән «Ата өе» («Ata Evi», 1949) [28] исемле беренче китабында бер гаилә язмышы катлаулы ижтимагый-сәяси вакыйгалар яссылыгында сурәтләнә. Хикәяләүче романның беренче өлешендә өч буын кешеләре бергә яшәгән традицион төрек гаиләсе, гаилә эчендә хатын-кызның хокуксызлыгы, ата кешенең көчле роле белән таныштыра. Адвокат булып эшләүче ата, гаиләнең матди хәлен никадәр яхшы кайгыртса да, хатынына һәм балаларына мөнәсәбәттә бер деспот итеп күз алдына бастырыла. Ире никадәр кыйнап, җәберләп яшәсә дә, ана кеше иренең авыр көннәрендә төп ярдәмчесе булып кала.

Мөселман гаиләсендәге ана кешенең сабырлыгы, золым күрүенә карамастан, иренә булган тугрылыгы мәсьәләсе – татар әдәбияты өчен дә хас тема. Орхан Кямалның әлеге романындагы ана образы белән Г.Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш» (1900) драмасындагы Әсма, «Бай угълы» (1902) романындагы Бәдрия арасында янәшәлек уздырырга мөмкин. Акыллы һәм түземле татар хатыннары да ирләренең яманлыкларына гел яхшылык белән җавап бирә, «җан тәслим кылдыкларында» яннарында була.

Алда Г.Исхакый һәм Г.Ибраһимов әсәрләре мисалында телгә алынган килен-кайнана арасындагы катлаулы мөнәсәбәт Орхан Кямал романында да урын ала. «Ата өе»ндә электән кимсетүле мөнәсәбәт күреп яшәгән кайнана, үз чиратында, килененә начар мөнәсәбәттә: улына гел шикаять итеп, аларны талаштырып яши. Әсәрне укыгач, күпчелек мөселман гаиләләрендә ир-хатын һәм кайнана-килен мөнәсәбәтләренең берничә буын традицион хәлдә дәвам итүе аңлашыла.

Романда икенче мөһим сюжет сызыгы гаиләнең беренче дөнья сугышы алды (туган ягы Аданада яшәүләре), сугыштан соңгы (Конья районына күченүләре) һәм Бәйруттагы хәлен илдәге тарихи үзгәрешләргә бәйләп аңлатуга нигезләнгән. Сугыштан соң илдәге икътисадый хәл тәэсирендә бу гаилә эчендә матди проблемалар башлана, бу, үз чиратында, ата кешенең гаилә кешеләренә булган мөнәсәбәтен тагын да миһербансызландыра. Җитәкчелек белән сәяси каршылыкка кергән ата кеше, гаиләсен алып, Бәйрутка качарга мәҗбүр була. Бу гаилә чит туфракларда, юксыллыкта газап чигеп, ватанын сагынып, бик авыр көннәр кичерә. Аталары вафатыннан соң, гаилә көч-хәл белән туган якларына кайтып егыла. Символик эчтәлекле «Ата өе» романының исеме туры мәгънәсендә адвокат ата кешенең йорты, гаиләсе кебек аңлашылса, күчерелмә мәгънәдә туган җир, туган туфрак, Ватан төшенчәләрендә килә. «Ата» аллегорик-символик образы күчерелмә мәгънә алып, кодрәтле, фәкать заман үтү белән көчен югалткан госманлы дәүләте кебек укыла башлый.

Гомумән, романның баш герое яшь егетнең аңлатулары аша, Орхан Кямал, бер гаилә язмышын ил күләмендәге сәяси вакыйгалар фонында сурәтләү белән бергә, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрне ачыклауга да урын бирә. Гаиләдә ата кешенең көчле авторитеты, бердәмлек һәм эчке кануннар ныклыгы гаилә әгъзаларын сәяси һәм икътисадый афәтләрдән саклап кала.

Җөмһүрият чоры төрек гаиләсе моделе, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр төрек әдәбиятының мәшһүр каләм иясе Решат Нури Гөлтекинның (1889-1956) «Яфрак коелуы» («Yaprak Dökümü», 1949) [29] романында гыйбрәтле рәвештә тасвирлана. «Яфрак коелуы» романы – егерменче гасыр төрек классик әдәбиятының иң мәшһүр һәм психологик осталык белән язылган әсәрләрдән берсе. Бер гаиләнең таркалуын аңлаткан бу роман эчке рухы белән Садри Җәләлнең «Дим буенда» (1914) [30] повестена аваздаш. Ике әсәрдә дә ата-ананың киләчәк белән бәйле өметләренең акланмавы, матур бер гаилә балаларының бәхетсез язмышка дучар булуы, заман узу белән яшәгән йортларының да хәрабә хәленә килүе эчке бер сызлану аша бирелгән. Әсәрләрдә вакыйгалар сурәтләнгән заман төрле булса да, үзәктә гаилә, гаиләдә ата-ананың бурычы, гаилә һәм җәмгыять, намуслы яшәү кебек мәңгелек мәсьәләләр яктыртылган.

Р.Н.Гөлтекинның «Яфрак коелуы» романында традицион госманлы чоры тәрбиясе алган ата белән заманча яшәргә теләгән балалары арасындагы каршылык һәм аның нәтиҗәләре сурәтләнә. Әсәрдән күренгәнчә, баш герой Али Риза бәй гаилә коруга җитди карый, өйләнүне «яңа бер дәүләт кору кадәр әһәмиятле бер эш» дип уйлый. Ул, фидакарь ата, балаларын матди яктан гына түгел, рухи яктан да тәэмин итәргә омтыла, аларны чын күңелдән ярата, үзе дөрес дип уйлаган яшәү принципларында тәрбияләргә тырыша. Төрек җәмгыятендәге икътисадый һәм мәдәни үзгәрешләр чорында яшәгән Али Риза бәй бу яңалыкларга җайлашырга яки каршы торырга әзер булмый. «Алтын яфрак» ширкәтендә бергә эшләүче егет Али Риза бәйгә болай ди: «Бөек Мухарәбәдән (беренче дөнья сугышы) соң бөтен дөньяда гаҗәеп бер уяну булды. Хәзер кешеләр инде сезнең заман кешеләре түгел. Күзләрнең ачылуы гамәлләрне, зур теләк-омтылышларны арттырды. Беркем дә элекке кебек үз хәленнән риза түгел. Бу үтәли җил нәтиҗәсендә иске әхлак кагыйдәләренең җимерелеп үзгәрмәвендә ничек форсат күрерсез» [29: 11], ди. Ягъни яңа җәмгыять аренасына иске әхлакый кыйммәтләргә күрә яшәүче Али Риза бәй җиренә «күзләре ачык», «гамәлләре һәм теләк-омтылышлары арткан» «яңа заман кешеләре» килә.

Гаилә тормышы һәм ширкәттәге эше тыныч һәм салмак кына дәвам иткәндә, ул, намус эше дип, ширкәттәге хаксызлыкларга түзә алмыйча, эшеннән китеп пенсиягә чыга һәм гаилә рәислеген банкта эшләүче бердәнбер улы Шәүкәткә тапшыра. Ул бу вазифаны иң зур бәхет, «король булган бер кешенең башына таҗ» [29: 35] кидерү дип саный һәм вакыйгаларны кырыйдан күзәтүче роленә күчә.

Гаиләнең сакланып калуында, гаилә алдындагы кыенлыкларны җиңеп чыгуда, әлбәттә, гаилә эчендәге «эчке шартлар» зур роль уйный. Ир белән хатын арасында бердәмлек һәм ярдәмләшү, аеруча, хатыннарның сабырлыгы һәм ата кешегә хөрмәте гаиләне таркалудан саклаучы мөһим сыйфатлардан санала. «Яфрак коелуы» романында Али Риза бәйнең хатыны Хәйрия ханым, авыр минутларда иренә терәк булмый, киресенчә, намус эше дип эштән китүенә «гыйсъян байрагы ача»: «Артык житәр… Әгәр бу эшне ташлау намус кирәге эше икән, ташла… Ләкин онытма ки кыйбатлылык көннән-көн арта. Кара, артык саклый алмыйм. Фәрештә кебек балаларың тыеп тора алмаслык хәлгә килә. Юклык йөзеннән балаларың берәр берәр коела башласа, ике кулым, уң бармагым якаңда булыр», [29: 35] дип, балалары ягына күчә. Шул рәвешле, ата белән балалары, ата һәм хатыны арасында туган упкын бер-бер артлы килгән уңышсызлыкларга юл ача.

Саклану көче зәгыйфь, үзара мөнәсәбәтләрдә гармония булмаган гаиләгә тышкы факторлар, аерым алганда, җәмгыятьтәге начар шартлар тизрәк үтеп керүчән була. Романда моңа кадәр гаиләсен җәмгыятьтәге начар гадәтләрдән саклап торган Али Риза бәйнең көчле ата позициясеннән арткы планга чигенүе буй җиткән улы һәм кызларында үз теләкләре белән яшәү теләген тудыра. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрдән әллә ни хәбәрләре булмаган саф күңелле балалары беренче адымнарында ук ялгышлыклар ясый башлый. Атасының каршы килүенә карамастан, юаш холыклы Шәүкәт Фәрхунда исемле җилбәзәк хатынга өйләнә һәм бу хатын тәэсирендә Али Риза бәйнең фәрештә кебек кызлары Ләйлә белән Нежла өйләрендә күңел ачу кичәләре оештыра башлый. Өйдәге кичәләр тагын да яхшырак булсын өчен, Фәрхунда тәэсирендә, Шәүкәт банкта акча үзләштерә һәм бераздан кулга алына. Хәерчелектән котылам дип, Нежла сирияле бер кешегә өченче хатын булып китә, Ләйлә исә бер адвокатның сөяркәсе булып яши башлый. Балаларының ялгышлыкларын күтәрә алмаган Али Риза бәй психологик авыру кичерә, гаилә әгъзалары

каршында элекке абруен югалта. Гаиләсенең таркалуын, тыштан искән көчле жил тәэсирендә корып коелган яфраклар шикелле, бабаларының бәхетсезлеккә дучар ителүен аңлый.

Әсәрдә кеше, гаилә язмышы вакыйгалар барган урын – хронотоп белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнә. «Яфрак коелуы» романында социаль тормыш белән бергә кешенең дә үзгәрешен сәнгатьчә раслауда йорт образы уңышлы кулланылган. Гомумән, гаилә һәм гаилә кешеләрен үз эченә алган йорт – бер-береннән аерылмас төшенчәләр, шунлыктан гаилә темасын чагылдырган барлык әсәрләрдә дә диярлек гаилә яшәгән йортны тасвирлауга аерым фикри-мәгънәви әһәмият бирелә.

Төрек әдәбиятындагы кебек татар әдәбиятында да йорт гомумкешелек кыйммәткә ия һәм илдәге иҗтимагый үзгәрешләргә бәйле рәвештә төрле мәгънәви яссылыкта чагыла. Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәрешен җентекле тикшергән А.Батталова, әдәби үрнәкләр мисалында, бу образның төрле мәгънәләрен ача: йорт – кешенең матди хәлен билгеләүче эмблема, йорт – күнегелгән тәртипләр, йорт – нигез – туган ил, туган җир, йорт – милләт, йорт – нигез – кеше нәселенең оясы һ.б. [31: 25-40]. Мәсәлән, С.Җәләлнең «Дим буенда» әсәрендә Исхак мирза йортының һәм утарының таркалуы аерым бер гаиләнең һәм нигезнең генә түгел, бәлки мирзалар социаль катлавының юкка чыгуын да символлаштыра. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда татар җәмгыяте традицияләре, иске тормыш тәртипләре йорт образында тупланган. В.Әминева карашынча, «Туган йорт, гаилә һәм җәмгыять тәртипләре, гомумән алганда, татар халкы тормышында үзәк урынны били һәм дини карашлар белән тыгыз бәйләнештә тора» [32: 57].

Р.Гөлтекинның «Яфрак коелуы» романында Али Риза бәйнең йорты гаиләсен тышкы факторлардан саклаучы бер крепость-дивар, йорт эче үз яшәү кануннары, яшәү рәвеше булган бер дәүләт мәгънәсендә килә. Эшләгән чагында Али Риза бәй өчен атасыннан калган йорт хозур һәм киләчәккә өмет символы булып тора. Гаиләдә авторитеты зәгыйфьләнә башлагач, бу өйнең саклау көче кими башлый. Тышкы факторларның һәм яшәү шартларының үзгәрүе нәтиҗәсендә йорт җәһәннәмгә әйләнә. Тавыш-гауга еш була торган йортны балалар да «җәһәннәм» дип атый [29: 52]. Йорт белән баш каһарманның фикерләре һәм яшәү рәвеше арасында параллельлек үткәрелә: иҗтимагый-мәдәни яңарыштан «артта калган» һәм олыгая баручы Али Риза бәй кебек өе дә искергән, тарала, туза башлаган. Өй белән бергә аның эчендәге кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр дә «туза», гаилә таркала.

Бер гаилә фаҗигасен сурәтләгән «Яфрак коелуы» романында Р.Н.Гөлтекин төрек тормышында аерым шәхес бәхете өчен «кечкенә бер дәүләт» статусында булган гаиләнең, гаилә эчендәге бердәмлекнең ни кадәр әһәмиятле булуын күрсәтә һәм, иң мөһиме, гаиләдә ата кешенең авторитеты булырга тиешлеге фикерен уздыра.

1950 еллардан башлап сәнәгатьнең үсүе нәтиҗәсендә авыллардан шәһәргә күчеш арта башлый, нәтиҗәдә, авыллардагы киң гаиләләр таркала, шәһәр җиренә ата-ана һәм баладан формалашкан гаиләләр китә. Ил күләмендә төрле иҗтимагый үзгәрешләр булуга карамастан, бүген дә авыл җирлегендә гаилә моделе, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр, аеруча хатын-кызның гаиләдәге урыны, кияүгә чыгу, өйләнешү кебек гадәтләр кебек дәвам итә. Бу тема хәзерге чор язучысы Хәдичә Биләннең «Игътибар ителмәгән хатыннар» («Umursanmayan kadınlar», 1989) [33] исемле хикәяләр җыентыгында чагыла: аларда гаиләдә ата-кыз мөнәсәбәте, кызларның язмышында атаның роле мәсьәләсе үзәккә алына. «Сунактагы корбан» («Sunaktaki[1] Kurban») хикәясендә әниләре үлгән гаиләдә бөтен җаваплылык яшь кыз җилкәсендә кала. Башта ир туганнары гаилә корсын дип, атасы кызын үз заманында сөйгән кешесенә кияүгә бирми. Еллар узгач, кызының фикерен дә сорамыйча, «синең дә үз ояң булсын инде» дип, үзе теләгән кешегә биреп җибәрә. «Уяну» («Uyanmak») әсәрендә дә ата кеше, кырда эшләргә кеше калмый дип, кызы Мөкатдәснең тормышын көйләү хакында уйламый. Вакыт үтү белән, атасы һәм үги анасының золымыннан котылу өчен, Мөкатдәс яратмаган кешегә кияүгә чыгарга мәҗбүр була һәм, әлбәттә, бәхетсез язмышка дучар ителә. Хатын-кызларга эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган төрек авылында бүген дә гаилә – хатын-кыз өчен «кечкенә бер дәүләт», «яшәү үзәге» булып санала, чөнки ул бары тик гаилә чикләре эчендә хәрәкәт итә һәм гаилә башлыгы саналган атасына яки иренә буйсынырга мәҗбүр була.

[1] сунак – дини йолаларда нәзер корбаны чалынган таш.

Шәһәрдә эш мөмкинлекләре киң булганлыктан, белем дәрәҗәсенә карап, ирләренең ризалыгы белән эшләүче хатын-кызлар саны көннән-көн арта. Әмма бу очракта мәсьәләнең икенче ягы калкып чыга. Нәтиҗәдә, хатын-кызларның күпчелеге гаиләсенә, үзенә, баласына һәм иренә кирәкле вакытны багышлый алмый, ә бу, үз чиратында, гаилә эчендәге күңелсезлекләргә юл ача, аның нигезен какшатуга китерә. Гаилә темасы соңгы елларда күбрәк хикәя жанрында һәм аеруча хатын-кыз язучылары иҗатында киң чагылыш таба. Төрек җәмгыятендәге һәм гаиләсендәге хатыннарның хәлен һәм психологиясен яхшы аңлаган әдибәләр бу проблеманы тагын да тәэсирлерәк итеп сурәтли. Хәзерге чор язучысы Җәмилә Чакырның «Сибәл һәм Өрек агачы» (1990) [34] исемле әсәреннән күренгәнчә, ир белән хатын-кыз тигез хокуклы булган җәмгыятьтә авырлык тагын хатыннар җилкәсендә. Гаиләсенә матди яктан ярдәм итәргә һәм үзен эш җирендә күрсәтергә теләгән Сибәл өендәге эшләргә дә җаваплы. Ире, ярдәм итәсе урынга, аның эштән китүен, кайнанасы белән бергә яшәвен тели. Сибәл үз чиратында хатын-кыз ирегенең яклый, хатыннарның өйдә ирләренә һәм кайнаналарына хезмәтче булырга тиешлегенә каршы чыгып, аларның да эш урыннары булу фикерен хуплый.

Соңгы елларда язылган һәм төрек җәмгыятендәге төрле гаилә типларын яктырткан әсәрләрнең күбесе өчен уртак мотивлар – гаиләдә ата кешенең роленең ныклыгы, ир белән хатын арасындагы аңлашылмаучанлык, ата-ана һәм бала, ата һәм кыз арасындагы мөнәсәбәт, хатын-кызларның хокукы, золым, хыянәт кебек мәсьәләләр. Шулай да ерак үткәннән алып, бүген дә төрек культурасында гаилә җәмгыятьнең тотрыклылыгы һәм кешенең яшәеше өчен, иң әһәмиятле шартлардан санала. Үзенең матур традицияләрен саклауга зур игътибар биргән бу халыкта гаилә эчендәге күркәм гадәтләр, күршеләр һәм якын туганнар белән җылы мөнәсәбәтләр яшәвен дәвам итә.

Нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә мөмкин. Җәмгыятенең төрле үсеш баскычларында күзәтелгән тарихи, социаль, сәяси һәм мәдәни үзгәрешләргә карамыйча кешелек тарафыннан барлыкка китерелгән гаилә кыйммәтләре үзенең тотрыклылыгы, буыннан-буынга тапшырылып килү сыйфаты белән аерылып тора. Нигездә, ата-ана һәм балалар буыныннан формалашкан гаиләдә һәр ике буынның берсе каршында матди, тәрбияви һәм эмоциональ бурычлары бар. Кечкенә бер дәүләт статусы буларак саналган гаиләнең үз эчке кануннары, нәселдән-нәселгә күчеп килгән шәхси яки милли-этник гадәтләре булырга мөмкин. Җәмгыятьнең бер күзәнәге булганга, гаилә үз чорына хас рухи-әхлакый һәм мәдәни сыйфатларны да үзендә чагылдыра, димәк, шул мәгънәдә җәмгыятьнең көзгесе ролен үти.

Гаилә тормышын сурәтләүгә татар һәм төрек әдәбиятларының һәр чорында бердәй әһәмият бирелгән. Күзәтүләр һәр ике әдәбиятта уртак һәм мәгълүм дәрәҗәдә аерымлыклар булуны күрсәтте. Охшаш мотивлар татар һәм төрекләрнең тугандаш халыклар, рух-калеб һәм тел якынлыгы, XX гасыр башына кадәр бәйләнешләрнең аеруча көчле булуы белән аңлатыла. Татар халкының, дәүләтен югалтып, Россия империясендә милли-колониаль изелүгә дучар ителүе, руслар даирәсендә яшәп, һәрдаим юкка чыгу куркынычы белән санлашып яшәве бу теманы тасвирлауда аерымлыкларга китерә. Гаилә хәятен сурәтләү аша милли үзенчәлекләр, рухи кыйммәтләр калкытып куела. Хәзерге татар һәм төрек әдәбиятларында глобальләшү шартларында милләт буларак сакланып калу юлы гаилә кыйммәтләренең тотрыклылыгы белән билгеләнә дигән фикер үткәрелә. Гаилә – сәламәт җәмгыятьнең нигезе, шәхес тәрбияләүдә, югары әхлак нормаларын буыннан-буынга тапшыруда хәлиткеч вазифа башкара.

**Әдәбият**


1. *Aytaş A.* Sosyal Değişim Sürecimiz İçerisinde «Zehra, Aşk-I Memnu, Yaprak Dökümü, Kiralık Konak Ve Baba Evi» Romanlarında Aile Kavramı Hakkında Bazı Tespitler www.gazi.edu.tr
2. *Галиуллина Г.Р., Ильдарханова Ф.А., Галиева Г.И.* Этнокультурные традиции как основа укрепления семьи. Казань: Изд-во «Отечество», 2011. 118 с.
3. *Абилов Ш.Ш., Хисамов Н.Ш.* «Кыйссаи Йосыф» // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда: Т. 1: Урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 116-157.
4. *Миннегулов Х.Ю.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казан: Ихлас, 2014. 288 с.
5. *Сибгатуллина А.Т.* Метаморфозы панегирического жанра в татарской литературе // TATARICA. 2013. №1. С. 135-143.
6. Татар әдәбиятыннан хрестоматия: татар урта гомуми белем мәкт. һәм гимназияләренең 9 нчы с-фы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен / Төз. Х.Й.Миңнегулов, Ш.А.Садретди-

нов.Тулыл. 2 нче басма. Казан: Мәгариф, 2000. 383 б.
7. *Исхакый Г.* Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре [төз., текст, иск. һәм аңлат. әзер. Л.Гайнанова, кереш һәм ахыр сүз авт. И.Нуруллин , Һ.Мәхмүтов, Л.Гайнанова]. Казан: Татар. кит. нәшр.,1991. 671 б.
8. *Әмирхан Ф.* Әсәрләр: Дүрт томда. Т. 2: Повестьлар, роман һәм драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр.,1985. 488б.; Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 4: Пьесалар (1900-1918). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 496 б.; Фәйзи.М. Әсәрләр [Төз. һәм кереш сүз авт. Т.Ш.Гыйлаҗев]. Казан: Мәгариф, 2007. 293 б.; *Тинчурин К.* Сайланма драмалар һәм комедияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 542 б.
9. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Мирхәйдәр Фәйзи: Тормыш юлы һәм иҗаты. Казан: Казан университеты, 2011. 80 б.
10. *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907-1929). Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 508 б.; Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 476 б.
11. *Такташ Һ.* Әсәрләр: 3 томда. Т. 2: Драматургия һәм проза. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 479 б.
12. *Такташ Һ.* Әсәрләр: 3 томда. Т. 1: Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 528 б.
13. *Кутуй Г.* Тапшырылмаган хатлар. 8 басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 80 б.
14. *Еники Ә.* Әсәрләр: 5 томда. Т. 2: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 447 б.
15. *Гыйлаҗев А.М.* Балта кем кулында? Роман [кереш сүз авт. Ф.Ганиева]. Казан: Татар. кит нәшр., 2008. 318 б.
16. *Гыйлаҗев А.М.* Сайланма әсәрләр: Алты томда. Т. 1: автобиографик эссе, юлъязма, роман-хатирә, хатлар / [томны төз., текст, иск. һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. М.Хәбетдинова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 687 б.
17. *Садриев Ф.* Бәхетсезләр бәхете: Роман-трилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 902 б.
18. *Галиуллин Т.* Сәет Сакманов: Роман-трилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 656 б.
19. Türk Aile yapısı www.genelbilge.com.
20. *Yeni Türk edebiyatı (1839-2000),* 5.baskı, Editör Dr.Ramazan Korkmaz, Ankara, Grafiker Yayınları, 2009. 640 s.
21. *İldokuz F.* Kadın Öykü Yazarlarında Aile (1970-1980), Marmara Üniversitesi Türk Dili ve Edebiyatı Anabilim Dalı Yeni Türk Edebiyatı Bilim Dalı, Yüksek Lisans Tezi, İstanbul, 2011. 178 s.
22. *Харрасова Р.Ф.* Әдәби багланышлар яктылыгында. Казан: «РПФ Гарт», 2002. 261 б.
23. *Mithat A.* Felsefe-i Zenan. İstanbul, Sel yayıncılık, 2008. 160 s.
24. *Kemal N.* İntibah. İstanbul, say yayınları, 2010. 112 s.
25. *Nazım N.*. Zehra. İstanbul, Bilge Kültür Sanat, 2012.160s.; *Uşaklıgel H.Z.* Aşk-ı Memnu. İstanbul, Özgür yayınları, 2001. 514 s.; *Rauf M.* Eylül /Çevirmen Kemal Bek. İstanbul, Özgür yayınları, 2002. 275s.
26. *Duben A.*, Behar C. İstanbul Haneleri. İstanbul, İletişim yayınevi, 1998. 283 s.
27. *Güntekin R.N.* Çalıkuşu. İstanbul, İnkılâp Kitabevi, 2001. 120 s.
28. *Kemal O.* Baba Evi. İstanbul, Tekin yayınları, 2000. 102 s.
29. *Güntekin R.N.* Yaprak Dökümü. İstanbul, İnkılâp Kitabevi. 1999. 141 s.
30. *Җәләл С.* Дим буенда. Повесть һәм хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 252 б.
31. *Батталова А.Д.* Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар): Монография. Казан, 2009. 132 б.
32. Әдәби әсәргә анализ ясау / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева. Казан: Мәгариф, 2005. 111 б.
33. *Bilen H.* Umursanmayan Kadınlar. İstanbul, Bilgi yayınevi, 1989. 232 s.
34. *Çakır C.* Gelincikle Uyanmak, 'Sibel ve Erik Ağacı', İstanbul, Ekin yayınları, 1990. 109 s.

# ПРОБЛЕМА СЕМЬИ И ОБЩЕСТВА В ТАТАРСКОЙ И ТЮРКСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

**Рамиля Яруллина Йылдырым,**
Адыяманский университет,
Турция, 02040, г.Адыяман, Квартал Алтыншэхэр, ул.3005, No: 13,
ramile@inbox.ru.

Во вступительной части статьи выявляется роль семьи как ячейки общества, рассматривается трансформация модели семьи в обществе под влиянием исторических условий, ключевых тенденций развития культуры. В основной части на примере анализа литературных произведений рассмотрены проблемы, с которыми сталкивается семья, и процессы обновления семьи.

Краткий обзор литературных произведений XIX-XX вв., созданных в период становления и развития национальных идей, показывает, как изменяются представления о семье в литературе конкретного периода. Так, в литературе начала XX века вопросы служения нации рассматриваются в неразрывной связи с институтом семьи, проблемами воспитания, сохранения национальных традиций и традиционной системы ценностей. В дальнейшем, в литературе 1920-х гг., взгляд на семью меняется в связи с изменениями в обществе, когда интересы государства стали преобладать над интересами отдельно взятой личности. Позднее в татарской литературе взаимоотношения личности, семьи и общества раскрываются в социальном и психологическом ключе.

Изменения в турецком обществе произошли благодаря реформаторскому движению эпохи Танзимата. На примере турецкой литературы раскрывается, как меняется характер взаимоотношений между членами семьи, взгляды на роль отца и матери под влиянием новых европейских веяний, исторических и культурных событий.

**Ключевые слова:** татарская литература, турецкая литература, эпоха, модели семьи, общие нравственные ценности, судьба личности.